Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Урта Кумор авыл җирлеге Советы

# КАРАР

2021 елның 23 сентябрь № 22

Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2007 елның 26 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турындагы Нигезләмәне «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга яраклаштыру максатларында Урта Кумор авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2007 елның 26 сентябрендәге 28 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 13 статьясына , 4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7 нче пуктчаны өстәп, үзгәрешләр кертергә:

7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Ю.И.Исынбаев